2019 елның 26 декабреннән № 2619
ТР Сәламәтлек саклау
министрлыгы боерыгына
№ 2 кушымта

Өйдә үпкәләрнең озакка сузылган ясалма вентиляциясен үткәрү буенча чаралар оештыруның тәртибе

1. Әлеге Тәртип өлкән халыкка паллиатив медицина ярдәме күрсәткәндә өй шартларында үпкәләрнең озакка сузылган ясалма вентиляциясен (алга таба – ҮЯВ) оештыру буенча чаралар үткәрү кагыйдәләрен билгели.

2. Пациентка (аның законлы вәкиленә) йорт шартларында озакка сузылган ҮЯВ үткәрү өчен кирәкле медицина эшләнмәләрен һәм җиһазларын тапшыру турында карар пациент амбулатор шартларда паллиатив медицина ярдәме ала торган медицина оешмасының табиблык комиссиясе тарафыннан 2019 елның 10 июлендәге № 505н Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының боерыгы (алга таба – 2019 елның 10 июлендәге № 505н РФ ССМ боерыгы) белән расланган Паллиатив медицина ярдәме күрсәткәндә өйдә файдалану өчен, кеше организмы органнары һәм системалары функцияләрен саклау өчен билгеләнгән медицина эшләнмәләрен медицина оешмасыннан пациентка (аның законлы вәкиленә) тапшыру тәртибенә туры китереп кабул ителә.

Табиблык комиссиясе карары пациентның медицина документациясенә кертелә торган протокол белән рәсмиләштерелә.

3. Өйдә ҮЯВ үткәрүгә хәзерләү өчен пациентны паллиатив ярдәм бүлегенә (паллиатив медицина ярдәме койкасына) госпитализацияләү (күчерү) түбәндәгеләр булганда гамәлгә ашырыла:

өйдә ҮЯВ үткәрүгә хәзерләүне гамәлгә ашыручы медицина оешмасының өй шартларында пациентка ҮЯВ үткәрүгә күрсәтмәләрнең һәм каршы күрсәтмәләрнең булуын ачыклау турында табиблык комиссиясе карарлары;

өйдә үпкәләрнең ясалма вентиляциясен үткәрүгә пациентның (законлы вәкилнең) кушып бирелә торган форма буенча хәбәр ителгән ирекле ризалыгы (әлеге Тәртипкә № 1 кушымта);

әгәр гражданинның хәле үз ихтыярын белдерергә мөмкинлек бирә алмаса яисә законлы вәкилләре булмаса, «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге № 323-ФЗ Федераль законына туры китереп табиблар консилиумының карарлары;

ашыгыч хәлләр очрагында медицина оешмаларының ирешерлеге (тәүлек буе эшли торган телефон элемтәсе, килү вакыты 20 минуттан да артмаска тиеш);

Өйдә үпкәләрнең озакка сузылган
ясалма вентиляциясен үткәрү буенча
чаралар оештыруның тәртибенә
№ 2 кушымта

Тәкъдим ителгән үрнәк

Пациентның өй шартларының хәле турында анкета

1. Пациентның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта)

______________________________________________________________________

2.Туу датасы, елы, туу урыны________________________________________

3. Яшәү урынының адресы (теркәү урыны, чынында яшәү урыны)

______________________________________________________________________

4. Пациентның мәҗбүри медицина иминияте полисының номеры

______________________________________________________________________

5. Законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта)

______________________________________________________________________

6. Законлы вәкилнең туу датасы, елы, туу урыны

______________________________________________________________________

7. Законлы вәкилнең яшәү урынының адресы (теркәү урыны, чынында яшәү урыны)

______________________________________________________________________

8.Пациент яши торган торак бинаның төре:

☐торак йорт ☐торак йортның бер өлеше

☐фатир ☐фатирның бер өлеше

☐бүлмә

9. Торак бинада стационар телефонның булуы:

☐әйе ☐юк

10. Торак бинага кергәндә домофонның булуы:

☐әйе ☐юк

11. Кичектергесез коткару хезмәте өчен торакның үтемлелеге:

☐әйе ☐юк

12. Торак бинада булган энергетик ресурслар турында мәгълүмат:
12.1. Торак бинада электр белән тәэмин итү бар:
☐әйе ☐юк

Электр розеткалары җиргә тоташтырылган:
☐әйе ☐юк ☐мәгълүматлар юк

Өй шартларында медицина эшләнмәсен куллану өчен техник таләпләргә туры килә торган удлинительләр куллану мөмкин:
☐әйе ☐юк ☐мәгълүматлар юк

Өй шартларында медицина эшләнмәсен куллану өчен электр челтәрендә көчәнеш җитәрлек:
☐әйе ☐юк ☐мәгълүматлар юк

12.2. Торак бинада су белән тәэмин итү булу:
☐әйе ☐юк
☐үзәкләштерелгән су белән тәэмин итүсистемасы
☐үзәкләштерелмәгән су белән тәэмин итүсистемасы
☐кайнар су белән тәэмин итү ☐ салкын су белән тәэмин итү

12.3. Торак бинада үзәкләштерелгән су чыгару булу:
☐әйе ☐юк

12.4. Торак бинада җылыту системасы гыйбарәт:
☐үзәкләштерелгән җылыту системасы
☐үзәкләштерелмәгән җылыту системасы (күрсәтергә нинди) ____________________

13. Торак бинада пациентны янгын куркынычсызлыгы белән тәэмин итү турында мәгълүматлар:
Торак бинаның янгын куркынычсызлыгы таләпләренә туры килүе:
☐әйе ☐юк

Торак бинада янгын сүндергечнең булуы:
☐әйе ☐юк

Янгын сүндергечнең төзек хәлдә булуы:

☐әйе ☐юк

Торак бинада аварияле чыгу юлының булуы:
☐әйе ☐юк

Торак бинада янгын булу очрагында гамәлләр планы булу:
☐әйе ☐юк

14. Торак бинада һаваны кондиционерлау һәм суыту системалары бар
☐әйе ☐юк
Торак бинада һаваны кондиционерлау һәм суыту системалары гыйбарәт:
☐ кондиционер ☐ сплит-система ☐ һаваны дымландыру системасы
☐башка (күрсәтергә)____________________________________________________

15. Торак бинада техник яктан төзек суыткыч (суыткыч камера) булу:
☐әйе ☐юк

16. Ишекнең зурлыгы медицина эшләнмәсен тоткарлыксыз алып керергә мөмкинлек бирә
☐әйе ☐юк

17. Медицина эшләнмәсен торак бинада урнаштыру очрагында аның янына тоткарлыксыз якын килүне тәэмин итү турында мәгълүматлар:
☐әйе ☐юк ☐башка (күрсәтергә)________________________________________

18. Торак бинада йорт хайваннары булу:
☐әйе ☐юк
Төре һәм саны (җавап «әйе» булса) ________________________________________

19. Торак бинада бөҗәкләр һәм (яки) кимерүче хайваннар булу:
☐әйе ☐юк ☐мәгълүматлар юк

Пациент ____________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта), имзасы)

Законлы вәкиле_________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта), имзасы)
Дата____________

